**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**БОЕРЫГЫ**

26.08.2024

№ 284

**Россия Федерациясе Дәүләт Советының «Яшәү өчен инфраструктура» юнәлеше буенча комиссиясе секретариатын оештыру турында**

Россия Федерациясе Дәүләт Советының «Яшәү өчен инфраструктура» юнәлеше буенча комиссиясенең нәтиҗәле эшчәнлеген тәэмин итү һәм аның утырышларына материалларны үз вакытында әзерләү максатында:

1. Россия Федерациясе Дәүләт Советының «Яшәү өчен инфраструктура» юнәлеше буенча комиссиясе секретариатын оештырырга.

2. Россия Федерациясе Дәүләт Советының «Яшәү өчен инфраструктура» юнәлеше буенча комиссиясе секретариаты турында нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

3. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Россия Федерациясе Дәүләт советының «Төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, шәһәр тирәлеге» юнәлеше буенча эш төркеме секретариатын оештыру турында» 2021 елның 22 мартындагы 119 номерлы боерыгы;

Татарстан Республикасы Президентының «Россия Федерациясе Дәүләт советының «Төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, шәһәр тирәлеге» юнәлеше буенча эш төркеме секретариаты составына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 6 июлендәге 225 номерлы боерыгы;

Татарстан Республикасы Рәисенең «Россия Федерациясе Дәүләт советының «Төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, шәһәр тирәлеге» юнәлеше буенча эш төркеме секретариаты составына үзгәреш кертү турында» 2023 елның 25 маендагы 183 номерлы боерыгы;

Татарстан Республикасы Рәисенең «Россия Федерациясе Дәүләт советының «Төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, шәһәр тирәлеге» юнәлеше буенча эш төркеме секретариаты составына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 8 февралендәге 78 номерлы боерыгы.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2024 елның «26» августындагы
284 номерлы боерыгына
1 нче кушымта

**Россия Федерациясе Дәүләт Советының «Яшәү өчен инфраструктура» юнәлеше буенча комиссиясе секретариаты турында нигезләмә**

1. Россия Федерациясе Дәүләт Советының «Яшәү өчен инфраструктура» юнәлеше буенча комиссиясе секретариаты (алга таба – секретариат) Россия Федерациясе Дәүләт Советының «Яшәү өчен инфраструктура» юнәлеше буенча комиссиясе (алга таба – комиссия) эшчәнлеген тәэмин итү максатларында оештырыла.

2. Секретариат турыдан-туры комиссия рәисенә буйсына.

3. Секретариат Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

4. Секретариатның төп функцияләре:

комиссия утырышларын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру-техник чараларны эшләү һәм аларны үтәү;

комиссиягә кергән документларны гомумиләштерү, алар буенча белешмәләр һәм аналитик материаллар әзерләү;

комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча йомгаклау бәяләмәләре һәм тәкъдимнәр әзерләүне оештыру;

комиссиядә эш башкаруны оештыруны тәэмин итү.

5. Секретариат түбәндәгеләргә хокуклы:

комиссиягә йөкләнгән функцияләрне үтәү өчен кирәкле материалларны билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарыннан, иҗтимагый берләшмәләрдән һәм оешмалардан соратырга һәм алырга;

комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча экспертлык эшен һәм аналитик эш башкару өчен белгечләр җәлеп итәргә.

6. Секретариат түбәндәгеләргә бурычлы:

комиссиянең үз функцияләренә караган мәсьәләләр буенча карарларының үтәлүен тәэмин итәргә;

үз эшчәнлеге йомгаклары буенча комиссия рәисе алдында хисап тотарга.

7. Комиссия рәисе тарафыннан билгеләп куела торган секретариат җитәкчесе секретариатның эшенә җитәкчелек итә.

8. Секретариат җитәкчесе:

үзенә йөкләнгән функцияләр үтәлешен тәэмин итеп, секретариат эшчәнлегенә җитәкчелек итә;

дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар белән үзара мөнәсәбәтләрдә секретариат вәкиле буларак эш йөртә;

секретариат эшен оештыруны камилләштерү турында комиссия рәисенә тәкъдимнәр кертә;

секретариат функцияләрен гамәлгә ашыруга бәйле хезмәт урынындагы язышуны имзалый.

9. Секретариат җитәкчесе һәм аның әгъзалары секретариатка йөкләнгән бурычларның үтәлеше өчен шәхсән җаваплы була.

---

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2024 елның «__26__» августындагы
284 номерлы боерыгына
2 нче кушымта

**Россия Федерациясе Дәүләт Советының «Яшәү өчен инфраструктура» юнәлеше буенча комиссиясе секретариаты составы**

| | |
|---|---|
| Нигъмәтуллин<br>Рөстәм Камил улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, секретариат җитәкчесе |
| Айзатуллин<br>Марат Мансур улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры, секретариат җитәкчесе урынбасары |
| Әбүбәкерова<br>Элеонора Хәлил кызы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары |
| Азин<br>Юрий Николаевич | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсенең юл һәм төзелеш комплексларында инвестиция программаларын тормышка ашыру бүлеге мөдире |
| Вагыйзов<br>Айдар Рамил улы | Татарстан Республикасы Рәисенең Эксперт департаменты җитәкчесе урынбасары – Департаментның Икътисадый анализ идарәсе башлыгы |
| Вәлиев<br>Шамил Фирдүз улы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министр-лыгының мәгълүмат-аналитика идарәсе җыелма-аналитика бүлеге башлыгы |
| Галимова<br>Айгөл Илгизәр кызы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министр-лыгының икътисадый анализ һәм дәүләт программаларын формалаштыру идарәсе икътисадый анализ һәм төзелештә бәяләр кую бүлеге башлыгы |

| | |
|---|---|
| Гыймаев<br>Илшат Сәхәп улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары |
| Кудряшев<br>Владимир Николаевич | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары |
| Мәннанов<br>Рөстәм Марат улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсенең юл һәм төзелеш комплексларында инвестиция программаларын тормышка ашыру бүлеге баш киңәшчесе |
| Нәфыйгин<br>Альберт Илдар улы | Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе |
| Нурмөхәммәтов<br>Илнур Фәгыйль улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары |
| Нуретдинов<br>Рамил Наил улы | Татарстан Республикасы Рәисенең Эксперт департаменты Икътисадый анализ идарәсе баш киңәшчесе |
| Сибгатуллин<br>Илдар Нурзадә улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсе башлыгы |
| Спицкий<br>Денис Андреевич | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының мәгълүмат-аналитика идарәсе башлыгы |
| Урманов<br>Даян Ренат улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары ярдәмчесе |
| Фәйзетдинова<br>Гөлназ Рәис кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары секретариаты баш киңәшчесе |

| | |
|---|---|
| Фролов<br>Алексей Михайлович | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасары |
| Шәймәрданов<br>Раил Рашат улы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министр-лыгының икътисадый анализ һәм дәүләт программаларын формалаштыру идарәсе башлыгы |

___________